Эшне үтәү буенча кулланма

Татар теленнән белем һәм күнекмәләрне тикшерү өчен биремнәрне башкаруга 45 минут вакыт бирелә. Тәкъдим ителгән эш 2 өлештән тора.

Беренче өлеш 12 биремне үз эченә ала (А1-А12), сез алар арасыннан дөрес дип уйлаган җавапны сайлап алырга тиеш.

Икенче өлеш В1-В6 биремнәреннән тора. Әлеге биремнәр текстка бәйле рәвештә башкарыла. В1-В6 биремнәренә җавапны сез мөстәкыйль рәвештә формалаштырырга һәм язып куярга тиешсез.

Биремнәрне тәкъдим ителгән тәртиптә үтәгез. Аларны үтәү барышында сезнең өчен кыенлык тудырганнары килеп чыксса, әлеге биремне калдырып торып, алдагыларына күчәргә киңәш итәбез. Сез бу биремнәргә, вакытыгыз калган очракта, кабат әйләнеп кайта алачаксыз. Беренче өлештәге биремнәргә якынча 2 минут вакыт бирелә. Икенче өлештәге һәр биремгә 3-4 минут вакытыгызны сарыф итегез.

Дөрес җаваплар, катлаулылыкларыннан чыгып, 1 яки югарырак баллар белән бәяләнәләр. Әлеге балларны бергә кушканнан соң, сезгә гомуми балл чыгарыла, шуңа күрә мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җаваплар бирергә һәм күбрәк баллар җыярга тырышыгыз.

Сезгә уңышлар телибез !

4 вариант

1 өлеш (А)

Әлеге өлештәге биремнәрне (А1-А12) үтәгәндә, җавалар бланкында эшләнә торган бирем аста урнашкан, дөрес дип табылган җавап номеры шакмагына «Х» билгесе куегыз.

А1. Нечкә сузыклы сүзләрдән генә торган рәтне табыгыз.

1. урындык, тормыш, намус, кабык
2. каен, давыл, гөмбә, дага
3. кунак, сакчы, көймә, кәҗә
4. кеше, иген, керпе, нигез

А2. Яңгырау тартыклардан торган сүзне билгеләгез.

1. катык
2. мәгънә
3. чиләк
4. табигать

А3. Кайсы рәттәге сүзләрдә [w] авазы әйтелә?

1. витамин, вокзал, паровоз, вышка
2. авыл, тавык, савыт, аваз
3. паровоз, җавап, конверт, вафля
4. февраль, август, завод, вагон

А4. Кайсы рәттәге сүзләрдә ь хәрефе языла?

1. кур…ер, бәгыр..., кул...язма, об...ект
2. сәнгат..., итагат...ле, гам...сез, көн...як
3. ик...тисад, л...гота, суб...ект, пул..т
4. мәг...нә, кәгаз..., рол..., дөн...я

А5. Кайсы рәттәге сүзләргә – *лар, - лар* **күплек кушымчалары ялгана?**

1. вагон, кибет, малай
2. тавык, аваз, савыт
3. тиен, ябалак, дәфтәр
4. урман, миң, идән

А6. **Тамырдаш сүзләрне күрсәтегез.**

1. урак, урман, урды
2. көйлә, көйле, көйсез
3. сөлге, сөрт, сөртенде
4. карга, карлы, карсыз

А7. *Ташбака* **сүзенең ясалышын билгеләгез.**

1. ясалма
2. тезмә
3. парлы
4. кушма

А8. Бирелгән мәкальдә күп нокталар урынына кайсы кушымчалар ялгана?

Таныш... күп булса, табыш... күп булыр.

1. – ның
2. – ың
3. – ка
4. – тан

А9. **Санга туры килгән билгеләмәне күрсәтегез.**

1. предметның билгесен белдерә
2. предметны белдерә
3. предметның эшен, хәрәкәтен белдерә
4. предметның санын, исәбен белдерә

А10. **Түбәндәге мәкальгә туры килгән фигыль формасын билгеләгез.**
Кем эшләми, шул ... .

1. аша
2. ашамый
3. ашый
4. ашама

А11. **Төшеп калган сүзне табыгыз.**

“... эшне, хәрәкәтне, хәлне белдерәләр. Алар нишли? нишләде? нишләгән? нишләр? нишләячәк? сорауларына җавап бирәләр”.

1. фигыльләр
2. исемнәр
3. саннар
4. сыйфатлар

А12. Микъдар саны нәрсәне белдерә?

1. предметның төгәл исәбен
2. предметның саналу тәртибен
3. предметның билгесен
4. предметның эшен, хәрәкәтен

2 өлеш (В)

Әлеге өлештәге биремнәрне, тәкъдим ителгән текст ярдәмендә үтәгәндә, җавапларыгызны җавап бланкында В1-В6 саннарының уң ягына беренче шакмактан башлап языгыз. Һәр хәреф яки цифр аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар, санап үтелгәндә, аерым шакмакка куелган өтерләр белән аерыла. Җавапларны язганда буш шакмаклар калдырырга ярамый.

(1) Шул көннән башлап әти самавырны чишмә суыннан гына куйдыра торган булды.(2) Күршедә генә кое да бар югыйсә. (3) Суы да чип-чиста, тәмле, алып чыгу да җиңелрәк. (4) Чишмәдән китергәндә ике тапкыр тау менәсе бар.(5) Ә бу эш минем өстә.

В1. 3 нче җөмләдәге артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатның антонимын языгыз.

В2. 3 нче җөмләдәге сүз ясагыч кушымча ярдәмендә ясалган сүзне табып языгыз.

В3. 1 нче җөмләдән алмашлыкны язып алыгыз.

В4. 2 нче җөмләдән юлдан-юлга күчерергә мөмкин булмаган сүзләрне язып алыгыз.

В5. 3 нче җөмләдәге калын сузыклардан торган исемне төшем килешенә куеп языгыз.

В6. 1 нче җөмләдән [w] авазы булган сүзне язып алыгыз.